БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31 май 2019 ел № 189

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм аны куллану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Балтач муниципаль районы милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү системасын камилләштерү, аренда шартларында файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставының 29, 53 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2011 елның 21 маендагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 48 номерлы карары белән раслаган (19.12.2014, 16.07.2015, 11.11.2016 үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм аны куллану турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Нигезләмәнең 2.3. пунктының в) һәм г) пунктчаларында «Башкарма комитетының карарлар проектларын әзерли» сүзләрен «карарлар кабул итә» сүзләренә алмаштырырга;

- Нигезләмәнең 3.5 пунктында «район Советы тарафыннан раслана торган нигезләмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле вәкиле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

- Нигезләмәнең 4.1. пунктында в) түләүсез тапшыру шартнамәләре (бүләк итү пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин